РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ
СТАРОИКШУРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

422066, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Старая Икшурма, ул.Ленина, д.17
тел.8 (84362) 41-6-47

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ ИКШЕРМӘ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422066, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Иске Икшермә авылы, Ленин урамы, 17 йорт
тел.8 (84362) 41-6-47

e-mail: sik.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
23.10.2024

КАРАР
№ 23

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты турында**

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иске Икшермә авыл җирлеге Советының 10.03.2023 елгы 6 номерлы карары белән кабул ителгән Иске Икшермә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставын «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131 номерлы Федераль законга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иске Икшермә авыл җирлеге Советы

карар кылды:

1. Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын раслау турында» 10.03.2023 ел, №6 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектын расларга (кушымтада бирелә).

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иске Икшермә авыл җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иске Икшермә авыл җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты буенча «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иске Икшермә авыл җирлегендә гавами тыңлауларны һәм иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 10.03.2023 ел, №7 карары белән расланган тәртиптә 2024 елның 4 декабрендә 09.00 сәгатьтә Иске Икшермә авыл клубында ТР, Саба районы, Иске Икшермә авылы, Пушкин урамы, 2 нче йорт адресы буенча ачык тыңлаулар үткәрергә.

4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иске Икшермә авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне 2024 елның 3 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иске Икшермә авыл җирлеге Советына җибәрергә.

5. Махсус мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иске Икшермә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты турындагы карарны халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарны, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иске Икшермә авыл җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектын, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иске Икшермә авыл җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен бастырып чыгарырга:

Татарстан Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы Иске Икшермә авылы, Пушкин ур., 2 йорт; Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Татар Икшермәсе авылы, Гагарин ур., 16 йорт; Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Өч Нарат авылы, Татарстан ур., 41А йорт.

Иске Икшермә авыл җирлеге башлыгы А.И.Биккинин

Расланган

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Иске Икшермә
авыл җирлеге Советының
23.10.2024 № 23 карары белән

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының
Иске Икшермә авыл җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр
проекты

1. 5 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 21 пунктча өстәргә) :

"21) «шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру»;

2. 19 статьяның 5 пунктының икенче абзацында «1-7 пунктларында» сүзләрен «1 – 7 һәм 9.2 пунктларында»сүзләренә алмаштырырга.;

3. 34 статьяның 1 пунктындагы 26 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26) матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) Челтәр басмасын булдыру;»;

4. 41 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12.1 пунктчасы өстәргә:

"12.1) аның чит ил агенты статусын алуы;".

Расланган

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Иске Икшермә
авыл җирлеге Советының
23.10.2024 № 23 карары белән

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының
Иске Икшермә авыл җирлеге Уставына кертелә торган
үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына гражданнарның
тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның буенча
фикер алышуда катнашу тәртибе.

1. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иске Икшермә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иске Икшермә авыл җирлеге советына түбәндәге адрес буенча кертелә: 422066, ТР, Саба районы, Иске Икшермә авылы, Пушкин урамы, 3А йорт, язма рәвештә Иске Икшермә авыл җирлеге башлыгына.

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр җирлекнең махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерелгән яки хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча кабул ителә: https://pravo.tatarstan.ru.

2. Гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: 422066, ТР, Саба районы, Иске Икшермә авылы, Пушкин урамы, 3А йорт, шәхсән яисә почта аша (конвертта «Устав турында фикер алышу»тамгасы белән).

Иске Икшермә авыл җирлеге башлыгы А.И.Биккинин